Атюрьево районы «Әкият» («Сказка») балалар бакчасында дулкынландыргыч һәм бик моһим вакыйга узган.
Бакчада тәрбияләнvче балаларга кунакка махсус хәрби операция (СВО) катнашучысы килгән, дип язылган сайтларында. Очрашуда Шамиль Илдар улы Агишев, анын хатыны – балалар бакчасы педагогы Анастасия Ивановна Агишева, кызлары Венера һәм Аделина катнашкан.

Илдар улы Шамиль кvптән тvгел СВОда катнашкан урыннарыннан кайткан. Ул солдатларнын балаларга ярдәмнәре, хатлары, открыткалары, блиндаж шәмнәре очен рәхмәтле булулары турында сойләгән. Мондый шәмнәр солдатларны 5 сәгать жылыта һәм барысына да бик кирәк.
Беркайчан да балаларга камуфляж һәм форма кигән чын хәрбине шулай якын кvрергә туры килмәгән. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларнын кvзләре ничек балкыганын әйтеп тә бетереп булмый, чонки янәшәдә кочле, батыр, ышанычлы чын солдат.
Шамиль Илдар улы Агишев Туган иленне яратырга һәм сакларга, кочле, кыю, намуслы булырга омтылырга кирәклеге турында балаларга анла-шылырлык итеп сойләгән.
Мондый очрашуларнын әһәмияте зур, чонки балалар очен патриотик хисләр тәрбияләvдә бәяләп бетергесез эз калдырган. Очрашу азагында балалар кунакка батырлыгы, сабырлыгы, кыюлыгы очен рәхмәт белдергәннәр. Хәзер алар тогәл беләләр - герой булып тумыйлар, геройга әвереләләр...
Геройлар безнен арада яшиләр.